КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 913

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт

учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсендә:

«Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы» бүлегенең 6 пунктындагы 2 графада «1,0» саннарын «1,2» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» бүлегендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4. | Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә икътисадый эшчәнлек төре буенча хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеш темплары, процент | еллык | 101,5 | 101 | х | х | х | 102 | 102,7 | 103,7»; |

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «16. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары нигезендә ведомство буйсынуындагы предприятиеләр буенча мәгълүматлар кертүне тәэмин итү, процент | еллык | х | х | х | х | х | 100 | 100 | 100»; |

«Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы» бүлегенең 4 – 8 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4. | Сәнәгать буенча хезмәт җитештерүчәнлеге үсеше темпы, процент | еллык | 101,2 | 100,9 | х | х | х | 101,0 | 102,4 | 101,6 |
| 5. | Сәнәгать җитештерүе индексы, процент | квартал | 101,8 | 101,9 | 101,0 | 101,9 | 101,2 | 101,6 | 102,9 | 101,9 |
| 6. | Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә эшкәртү производстволарының өлеше, процент | еллык | 69,4 | 67,7 | х | х | х | 68,1 | 68,9 | 69,4 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Татарстан Республикасы экспортының гомуми күләмендә чимал булмаган продукция өлеше, процен | еллык | 54,1 | 57 | х | х | х | 56,8 | 73 | 75 |
| 8. | Узган елның шушы чорына карата чагыштырма бәяләрдә ваклап сату әйләнеше үсеше, процент | еллык | 102,8 | 104,5 | х | х | х | 101 | 101 | 102,1»; |

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» бүлегендә:
15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «15. | Кече эшкуарлык субъектларыннан һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалардан урнаштырылган сатып алуларның еллык гомуми күләменнән өлеше, процент | еллык | х | х | х | х | х | ≥ 15 | ≥15 | ≥ 15»; |

түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «18. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары нигезендә ведомство буйсынуындагы предприятиеләр буенча мәгълүматлар кертүне тәэмин итү, процент | еллык | х | х | х | х | х | 100 | 100 | 100»; |

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы» бүлегенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | «Транспорт» икътисадый эшчәнлек төре буенча хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеш темплары, процент | еллык | 97,7 | 100,0 | х | х | х | 100,8 | 101,9 | 100,9»; |

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» бүлегенең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «7. | Туучылар санының суммар коэффициенты | еллык | 1,652 | 1,617 | х | х | х | 1,558 | 1,633 | 1,678»; |

«Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы» бүлегенең 3 – 5 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. | Хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеш темплары, процент | еллык | 101,2 | 101,3 | х | х | х | 101,5 | 102,6 | 102,0 |
| 4. | Тулаем төбәк продуктның физик күләме индексы, процент | квартал | 101,6 | 101,5 | 100,6 | 101,3 | 100,6 | 101,3 | 102,5 | 102,1 |
| 5. | Тулаем төбәк продуктында төп капиталга инвестицияләр өлеше, процент | еллык | 30,2 | 24,5 | х | х | х | 25,0 | 25,0 | 25,0»; |

«Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле13 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «13. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары нигезендә ведомство буйсынуындагы предприятиеләр буенча мәгълүматлар кертүне тәэмин итү, процент | еллык | х | х | х | х | х | 100 | 100 | 100». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин